ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# “Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытына, шартларына һәм урыннарына карата өстәмә чикләүләр һәм Татарстан Республикасының кайбер закон актларының үз көчләрен югалтуын тану турында” Татарстан Республикасы Законының 2 һәм $2^1$ статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 11 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытына, шартларына һәм урыннарына карата өстәмә чикләүләр һәм Татарстан Республикасының кайбер закон актларының үз көчләрен югалтуын тану турында” 2015 елның 6 мартындагы 10-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2015, № 3, № 4, № 7 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның 1 пунктында “Җәмәгать туклануы хезмәте күрсәтү. Җәмәгать туклануы предприятиеләре классификациясе” ГОСТ Р 50762-2007” сүзләрен төшереп калдырырга;

2) $2^1$ статьяда “Аз алкогольле тонусны күтәрә торган эчемлекләр. Гомуми техник шартлар” ГОСТ Р 52845-2007” сүзләрен төшереп калдырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты
Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2016 елның 22 феврале
№ 9-ТРЗ